Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№4 (55)

7 февраль 2013 ел

## • Универ хәлләре

**УЗГАН АТНАДА КФУ ҺӘМ «ФОРД-СОЛЛЕРС-АЛАБУГА» ААЖ АРАСЫНДА КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ.** Әлеге хезмәттәшлеккә ике як та зур өметләр баглый. «Килешүнең нәтиҗәләре бик уңай булыр дип уйлыйбыз. Ул, һичшиксез, вузга, безнең компаниягә һәм, гомумән, республикабызга бик зур файда китерергә тиеш», – дип билгеләде «Форд-Соллерс-Алабуга» ААЖнең җитәкчесе Адиль Ширинов. SOLLERS – Россиянең иң алдынгы автомобиль җитештерү компанияләренең берсе. Ул дөньякүләм билгеле Ford, SsangYong, Toyota, Mazda һәм Isuzu кебек лидерлар белән тыгыз элемтәдә тора.

• • • •

1 февраль көнне булган **«СӘЛАМӘТЛЕК-2013» ТР ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫ СПАРТАКИАДАСЫНДА КФУ ҮЗЕН ЯХШЫ ЯКТАН КҮРСӘТТЕ**. Университетыбызның өстәл теннисы буенча җыелма командасы алтын медальгә лаек булды. Аның составында Конфуций институты директор урынбасары Ли Ланья, университетның гомуми физик тәрбия һәм спорт кафедрасы доценты А.М.Садыйкова, өлкән укытучылар Р.С.Мөхәмәтсафин, Р.М.Галиуллин, юридик факультет ассистенты А.Н.Шпагонов, А.М.Бутлеров ис. Химия институтының өлкән фәнни хезмәткәре А.И.Иванов бар иде. Чаңгы ярышы буенча составында Л.Т.Миннәхмәтова, М.В.Исаева, И.Ф.Нуруллина, И.Ф.Сафин, И.С.Ихсанов, А.А.Асхамов, Р.Ф.Зиннәтов, Н.Л.Николаева булган университет командасы көмеш медаль яулады.

• • • •

**2 ФЕВРАЛЬДӘ** Яр Чаллы филиалында Н.И.Лобачевский ис. Математика һәм механика институты вәкилләре белән **ОЧРАШУ БУЛДЫ**. Филиал КФУга кушылганнан соң, Яр Чаллыга институт хезмәткәрләренең яңа составта килүләре әле беренче тапкыр. Очрашуда хезмәттәшлек мәсьәләләре турында сүз алып барылды.

• • • •

**3 ФЕВРАЛЬ КӨННЕ** Алабуга институтында **АЧЫК ИШЕКЛӘР КӨНЕ БУЛДЫ**. Чарада абитуриентлар үзләре өчен бик күп мәгълүмат һәм кызыксындырган сорауларына җавап алды. Кунакларны институт директоры Елена Мерзон сәламләде һәм уку йорты турында сөйләде. Гомуми җыелыштан соң, абитуриентлар аудиторияләр буенча йөреп чыктылар, факультет деканнары белән очраштылар. Алар үз факультетлары тарихы, белгечлекләре, өстенлекле яклары турында мәгълүмат бирделәр. Аннан тыш, кунаклар өчен институт, аның музее, лабораторияләр буенча экскурсия оештырылган иде.

• • • •

**6 ФЕВРАЛЬДӘ** КФУның Яр Чаллы филиалында «Хәзерге заман шартларында фән, технология һәм коммуникация » дип исемләнгән **ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ ҮТТЕ**. Анда укытучылар унсигез төрле секциягә бүленеп чыгыш ясады.

• • • •

**6 ҺӘМ 7 ФЕВРАЛЬ КӨННӘРЕНДӘ** ЕС VOICES һәм «Постсоциализмның мәдәни-тикшеренү үзәге» фәнни-мәгариф үзәкләренә тарих фәннәре кандидаты, Ирекле университет (Берлин) профессоры **АНДРЕЙ МАКАРЫЧЕВ КИЛДЕ**. Кичә аның «Нормализация турында һәм Германиянең тышкы сәясәте: бердәйлек һәм җитәкчелек итү» исемле дебатлары узды.

• • • •

**8 ФЕВРАЛЬДӘ** инглиз теле атналыгы кысаларында УНИКСның концертлар залында **ИНГЛИЗ ТЕЛЕ ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫРЫЛАЧАК**. Чарага студент билетлары һәм хезмәткәр пропускы буенча керү бушлай. Чараны оештыручылар инглиз һәм америка мәдәниятен яратучыларны көтеп кала.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Диана Поварова, Руслан Гыйниятов фотолары

*Сулдан уңга: Р.Минзарипов, Л.Нугуманова, Т.Бархатова һәм М.Лукьянова*



# КФУга кисәтүләр юк!

**Динә МӨХТӘСИПОВА**, хәбәрче

5 февраль көнне Казанга Мәгариф һәм фән өлкәсе надзоры буенча федераль хезмәт җитәкчесе урынбасары Татьяна Бархатова һәм Мәгариф сыйфатын бәяләү идарәсе башлыгы урынбасары Марина Лукьянова килде.

Татарстан республикасына визитларын Мәскәү кунаклары Казан федераль университеты белән танышудан башлап җибәрде. Алар IT лицей-интернат, Физика институты лабораторияләрендә булды, КФУ ректоры Илшат Гафуров белән очрашты.

Алга таба Кайгыртучанлык советының утырышлар залында Казан шәһәре югары уку йорты ректорлары, Казан федераль университетының институт директорлары, факультет деканнары белән очрашу булды. Татьяна Бархатова мәгариф учреждениеләренең эшчәнлеген регламентацияләү процедурасы турында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, федераль хезмәт контроль чикләрен арттыра. 2010 елда – ике, 2011 елда – тугыз, 2012 елда – егерме лицензия туктатылган. Быел инде бу сан унтугызга җиткән. М.Лукьянова шулай ук югары белем бирү сыйфатын тикшерә торган система төзү, Дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре, укырга кабул итү процессына кертелгән төп үзгәрешләр кебек төшенчәләргә дә тукталды. Бүгенге көндә иң актуаль темаларның берсе булып, уку йортына кабул итү тора. 2013 елның беренче февраленә керү имтиханнары исемлеге һәм кабул итү кагыйдәләре билгеле булды. Бу уңайдан Казан федераль университеты бер кисәтү дә алмаган.

Алга таба вуз җитәкчеләре «Мәгариф турында закон»дагы үзгәрешләр, өстәмә белем бирүдә норматив база, халыкара аккредитация, дистанцион белем бирү кебек мәсьәләләр буенча да төгәл мәгълүмат алды.

Татьяна Бархатованың уку йортына визиты кичә дә дәвам итте. Ул Казан федераль университетына абитуриентлардан документларны электрон рәвештә кабул итү системасын тикшерде. Фундаменталь медицина һәм биология институты эшчәнлеге белән танышты.

## • Чара

# Кытайча Яңа ел белән!

**Дания ФАТЫЙХОВА,** хәбәрче

4 февраль көнне «УНИКС»та Казандагы Кытай студентлары Берлеге ачылуга һәм Кытай Яңа елын үткәрүгә багышланган концерт булды.

Кытайларда әлеге бәйрәм иң мөһимнәрдән санала һәм аның төгәл датасы юк. Ул ай фазасы нигезендә билгеләнә икән. Быел яңа елның беренче көне 10 февральгә туры килә. Яңа елны бәйрәм итәргә өлгермәгәннәр бу атнада кытайча Яңа елны каршылый ала.

Бәйрәмне оештыручылар, Кытай Яңа елы уңаеннан, үз халыкларының гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә багышланган үзенчәлекле күргәзмә оештырганнар. Мәҗлестә Кытай студентлары һәм аспирантлары Берлеге ачылу турында хәбәр иттеләр. Ул Кытай телен һәм традицияләрен өйрәнүчеләргә ярдәм итәчәк.

Тантананың икенче өлешендә студентлар Кытай милли уен кораллары рында үз остлыкларын күрсәтте. Кичә Кытай телендә «Без бер гаилә» күмәк җыры белән тәмамланды.



• Үткәнгә – нәтиҗә, киләчәккә – планнар!

# Яңа җитәкче белән беренче утырыш

**Динара ЗИННӘТОВА,**
Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институты

Шушы көннәрдә Массакүләм коммуникацияләр һәм социаль фәннәр институтының яңа директоры Мөхәрәмов Наил Мидхәт улы институт хезмәткәрләре белән җыелыш үткәрде. Очрашуда кафедраларның бүгенге халәте һәм институтның алдагы үсеш перспективалары турында сүз барды. Чарада Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор Ариф Межведилов та катнашты.

Беренче булып, журналистика кафедрасы җитәкчесе Светлана Шәйхетдинова чыгыш ясады. Хәзерге вакытта кафедрада «Казанская стужурка» исемле студентлар газетасы сайты эшләнә икән. Лаборатор уку газетасын булдыру, шул исәптән аның татар телендәге версиясен эшләү дә планлашатырыла. Моннан тыш, журналистика кафедрасы Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты белән берлектә «конвергент журналистикасы» юнәлеше буенча магистратура ачарга җыена. Бу эш белән беррәттән, «Визуаль мәгълүмат үзәге» дигән лаборатория булдыру буенча да эшләр алып барыла.

Татар журналистикасы кафедрасы җитәкчесе Васил Гарифуллин, әлеге кафедрада «Төбәк һәм милли журналистиканы өйрәнү» үзәген оештыру планлаштырыла, дип белдерде. Моннан тыш, биредә «Татар иҗтимагый-сәяси журналистика» һәм «Татар телендә телевизион журналистика» белгечлекләре буенча магистр программалары ачу турында да сүз барды.

Электрон массакүләм матбугат чараларының теориясе һәм практикасы кафедрасы җитәкчесе Елена Дорощук Интернет-медиа үзәге, Киберҗурналистика буенча тренинг үзәге проектлары белән таныштырды.

Гамәли политология һәм җәмагатьчелек белән элемтәләр кафедрасы доценты Дмитрий Мюллер хезмәттәшләренең республика һәм төбәк дәрәҗәсендә үтә торган инновацион тикшеренүләрдә зур уңышларга ирешүләре, белем бирү һәм фәнни эшкә яшь белгечләрнең тартылуы турында сөйләде.

Социология кафедрасы профессоры Клавдия Новикова үз чыгышында әлеге бүлекнең фәнни-тикшерену һәм социология белеме бирү үзәге буларак үсеш перспективаларын ассызыклады.

Директор, кафедра вәкилләренең сүзен йомгаклап, җыелышта яңгыраган планнарны хуплавын белдерде. Наил Мөхәрәмов төп игътибарны магистр программаларын эшләүгә юнәлтергә кушты. «Магистратура – ул товар, ә без университет студентларын гына түгел, бөтен төбәктәге студентларны беренче курстан башлап, үзебезнең магистр программалары белән кызыксындырырга тиеш», – диде.

• Юбиляр

# Чын Җир улы

**Нияз БИКТИМИРОВ,**
география фәннәре кандидаты, доцент



Җәүдәт Абдулла улы Хөсәенов 1948 елның 7 февралендә, Татарстанның Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында туа. Салкын кыш аенда тугангамы, балачагы бик кырыс, авыр була. Әле җиде ай гына тулган сабыйны әти-әни дигән кешеләр туганнары тиешле Нурулла абый һәм Бибинур апага тапшыралар.

Нурулла абый һәм Бибинур апаның балалары булмый, шул сәбәпле ятим Җәүдәт аларга сыена. Бу гаилә аны үз баласыннан да якын күрә. Нурулла абыйсын – әти, җиңгәсен – әни, дип ихлас күңелдән шатланып йөри. Ничек кенә булмасын, Җәүдәт ятимлекне үз күңеле, йөрәге белән тоеп яши. Материаль яктан аңа абыйсы һәм җиңгәсе барысын да булдырырга тырышсалар да, баланың рухи дөньясы китек була, моны ул башкаларга сиздермичә генә, үзе бик авыр кичерә. Җәүдәт алар алдында бурычлы булып калмый. Картлык көннәрендә хәленнән килгәнчә кадер-хөрмәтен күрсәтә. Аларның яхшылыгын, мәрхәмәтен, кешелеклелеген әле дә олы ихтирам белән искә ала.

Кече Чынлы, Иске Шәйморза мәктәпләрен тәмамлагач, Казан дәүләт педагогика институтының география бүлегенә укырга керә. 1967 елдан башлап, үз гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлый. География һәм экология, педагогика фәннәрен төрле яклап, киң һәм тирәнтен өйрәнә. Чүпрәле районы Кече Чынлы урта мәктәбендә, Казан шәһәре Киров районының дүртенче номерлы татар гимназиясендә директор вазыйфаларын башкара. Казан шәһәре Киров районы мәгариф бүлеге мөдире урынбасары булып эшли һәм шул елларда фәнни педагогика эшләре белән даими рәвештә шөгыльләнә. Нәтиҗәдә «Татар халкының табигать турындагы белемнәре нигезендә милли мәктәп укучыларында экологик мәдәният формалаштыру» фәнни-педагогик хезмәте барлыкка килә. 1998 елда шушы темага диссертация яклап, педагогика фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. Соңгы дәвердә ул аның белән генә чикләнеп калмый, ә бәлки «Мәктәп укучыларында экология мәдәниятен формалаштыруның концептуаль нигезләре: этнопедагогика аспекты» дигән темага докторлык диссертациясен яклый, профессор вазыйфасына лаек була.

Җәүдәт Хөсәеновның фәнни педагогик хезмәтләре буларак беренчесе, татар милли мәктәпләре өчен чыгарылган уку ярдәмлеге китабы – «Кызыклы география» (1982), татар мәктәпләре, гимназияләре өчен «Татарстан географиясе программалары» (1994), татар милли мәктәпләренең I-V сыйныфлары өчен чыгарылган «Экология фәне программалары» (1995) да дөнья күрә. Әлеге программалар республика күләмендә үткәрелгән конкурсларда катнашып, лаеклы урыннар алалар. Аның география, экология һәм тәрбия эшләренә багышланган хезмәтләре даими рәвештә республика, Россия матбугатында, ә соңгы вакытта чит илләрдә дә басылып килә.

Республиканың география укытучылары аның остаз-мөгаллим булуын инде күптән беләләр. Мәгариф өлкәсендәге хезмәтләре дә бәяләнә. Ул, укытучы булып эшләгән елларда ук, «Россиянең халык мәгарифе казанышы» билгесенә лаек була, укытучы-тикшеренүче баскычына күтәрелә. Югары уку йортында эшләгән чорда, Россия табигать белеме фәннәре академиясе аның фәнни хезмәтләренә югары бәя бирде, ул «Россия фәннәр акдемиясенең мөхбир-әгъзасы», «Фән һәм белем бирүдә атказанган эшлекле», «Фәнни мәктәпне нигезләүче» (2010) исемнәренә лаек булды. Россия табигать белеме фәннәре академиясе аны «Ватан фәнен үстерүгә керткән уңышлары өчен В.И.Вернадский исемендәге» көмеш медаль (2010), «Югары белем бирү өлкәсенә яңалык керткән өчен» алтын медаль (2012) белән бүләкләде.

Педагогик эшчәнлегенең күп өлешен үзе укыган Казан дәүләт педагогика университеты, хәзер инде Казан (Идел буе) федераль университеты белән бәйли. Бүгенге көндә Экология һәм географияинститутының«География һәм экологияне укыту теориясе һәм методикасы кафедрасы»нда педагогика фәннәре докторы, профессор булып тора. Ул – булачак география, биология һәм инглиз теле мөгаллимнәрен фәнсерләренә өйрәтүче олы галим һәм тәрбияче.

• Белем баскычлары

# «Чит ил тәҗрибәсен кулланабыз»!

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче

Казан федераль университетының эшчәнлек төрләрен атарга кушсаң, бик азлар гына аларның бөтенесен санап чыгар иде. Шуңа күрә сезне Идел буе төбәкара мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү һәм янадан әзерләү үзәге белән таныштырырга булдык. Аның өчен өстәмә белем бирү үзәгенең координаторы, гомуми белем бирү бүлеге өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты Сиринә Миңнегалим кызы Трофимова белән әңгәмә кордык.

**– Сиринә Миңнегалимовна, үзәгегез, аның эшчәнлеге белән якыннанрак таныштырсагыз иде.**

– Аерым структура буларак, без 2011 елның август айларында эшли башладык. Аңа кадәр ТР Мәгарифне үстерү институты буларак яшәдек, хәзер Казан федераль университетына карыйбыз. Безнең төп эшебез – укытучыларның белемнәрен камилләштерү буенча курслар алып бару. Мәгариф өлкәсендә булган бөтен яңалык белән танышып барып, аны укытучыларыбызга вакытында җиткерү – төп максатыбыз. Һәр укытучы биш елга бер мәртәбә үз белемен камилләштерергә тиеш. Чит илләрдә бу гамәл һәр ел саен башкарыла. Курсларның төрле юнәлешләре бар һәм без аларда чит ил тәҗрибәсен кулланырга тырышабыз. Һәр фәннең үз укытучысы билгеләнгән.





**– Димәк, Сездә укытучыларың белеменәрен камилләштерү юнәлешенә өстенлек бирелә?**

– Юк, безнең махсус факультет дигән тагын бер юнәлешебез бар. Икенче төрле әйткәндә, яңадан әзерләү факультеты. Бу эшчәнлек 1991 елдан бирле бара. Биредә бер төрле фән укытучысы булган кеше бөтенләй башка юнәлеш буенча белем ала. Монда эш КФУ укытучылары белән берлектә алып барыла. Мисал өчен, укытучы тарих фәне буенча укый икән – Тарих институты, татар теле буенча укый икән, Филология һәм сәнгать институты мөгаллимнәре укыта. Укытучының югары белемле булуы шарт. Тормыш иминлеге нигезләре, физик тәрбия кебек фән белгечләре өчен урта һөнәри белем дә җитә.

**– Димәк, спорт та игътибардан читтә калмый?**

– Спортка да аерым басым ясала. Бу юнәлешкә караган дәресләрне гамәлдә күрсәтеп, аңлатып алып баралар. Бу укытучыларның сәламәтлекләре өчен дә бик файдалы. Алган гыйлемнәрен укучыларына кайтып күрсәтәләр. Хәзерге көндә спортның Казанда ни дәрәҗәдә югары куелуы да зур роль уйный. Стадионнарның ишекләре һәркем өчен ачык, Универсиадага бәйле күп чаралар үткәрелә.

**– Сездә генә кулланыла торган программалар бармы?**

– Бездә бүгенге көндә дистанцион укыту гамәлгә ашырыла. Башка югары уку йортлары арасында без, беренчеләрдән булып, мондый төр укытуны кертеп җибәрдек. Тәҗрибә инде икенче елын дәвам итә. Бу система бөтен фәндә дә каралган, шул исәптән татар теленнән дә. Укытучыларга хатлар җибәрәбез. Сораулары туса, безнең укытучылар белән турыдан-туры әңгәмә корып хәл итәләр.

**– Сез Идел буе төбәкләре өчен дә эшлисез. Алар ни дәрәҗәдә актив?**

– Россия укытучылары үзләренә уңайлы вакытта, алдан килешенеп, безгә белемнәрен арттырырга киләләр. Мисал өчен, 4-13 февраль көннәрендә Ерак Көнчыгыштан килгән делегация стажировка үтә. Алар бездә берничә юнәлештә белемнәрен камилләштерәчәк. Шунысы кызганыч: елдан-ел килүчеләрнең саны кими. Бу командировка чыгымнарын үзләре күтәрү белән бәйледер инде. Без үзебез дә чит төбәкләргә барып укытып кайтабыз. Мисал өчен, татар телен һәм башлангыч сыйныфларда укыту буенча Екатеринбург, Әстерханда булдык. Безнең үзәк барлыгын күп җирдә беләләр. Бу интернетта актив эшләвебез белән аңлатыла. Стандартларга өйрәтү һәм заманча технологияләрне кертү буенча да без беренче! Шушы дәрәҗәне төшермәү – безнең бурыч!

● Кечкенә галимнәр

# Наталья Әхмәтҗанова: «Студентлар белән аралашудан үземә ямь һәм тәм алам»

Зилә ФӘСХИЕВА,
хәбәрче

Уку дәверендә аеруча кызыксынып һәм яратып укыган фәннәремнең берсе психология иде. Сәбәбе: психологиянең, дөрестән дә, мавыктыргыч фән булуындадыр, ә бәлки укытучысының кызыклы һәм үтемле итеп сөйли белүендәдер. 3 ел дәвамында психологиянең төрле тармакларын төшендергән Наталья Виктор кызы Әхмәтҗанова лекцияләрен йотлыгып, бөтен игътибарыбызны биреп тыңлый идек, чөнки ул һәрвакыт тормышчан мисалларга таянды. Теориядән бигрәк гамәли якка басым ясавы да студентлар өчен күпкә кызыклырак иде. Психология курсы безнең өчен тәмам булса да, Наталья Викторовнаның көләч йөзе, шат тавышы һәрвакыт истә. Февраль аенда мөгаллимәбез үзенең 55 яшьлек юбилеен билгеләп үтәчәк. Шул уңайдан сәхифәбезнең бүгенге кунагы – Педагогика һәм психология институтының психология кафедрасы доценты Әхмәтҗанова Наталья Викторовна.





«Мәктәптә мин тарихны бик яраттым. Нигә икәнен белмим, ләкин минем өчен тарихтан да кызыклырак фән юк иде. Шулай язгандыр инде, киләчәгем тарих белән бәйләнмәде. Гуманитар юнәлеш буенча китү өчен, укырга керер алдыннан, чит телдән имтихан бирергә кирәк иде. Ә мин чит телне бөтенләй өйрәнмәдем, шул сәбәпле укырга да керә алмам инде дип уйладым... Ул елларда рабфакта укучыларны юллама белән техник уку йортларына кабул итәләр иде. Мин дә шулай эшләдем.

Студент еллары минем өчен тормыш мәктәбе булды. КАИ студенткасы булуым белән бер яктан горурлансам, икенче яктан бездә уку бик авыр иде. Ул елларда «КАИ – илнең иң авыр вузларыннан берсе» дигән исемне йөртте. Укыганда да күбебез өчен «өч»ле алу ул зур бәхет булды. Беренче ике курста үзем дә «өч»ләләр алганга артык кайгырмадым, укуның авырлыгы белән чагыштырганда, бу урынлы билгеләрдер, күрәсең. Ләкин тормышта укуны гына беренче урынга кую һәм бөтен көчеңне аңа сарыф итү дөрес гамәл түгел. Кызганычка каршы, студентларның күбесе, моны аңлап бетермичә, сәламәтлекләренә зыян сала. Үзем белән дә шулай булды... Өченче курс урталарында бик нык авырый башладым. Дәваланырга кирәк иде. Шул ук вакытта укуны да калдырасым килмәде, әмма деканыбыз миңа бер елга академ ял алып, укуны аннан соң дәвам итәргә тәкъдим итте. Башта куркып калсам да, мин нәкъ шулай эшләдем... Һәм бер дә үкенмим. Алга таба инде уку миңа җиңел бирелде. «Өч»леләрем инде бөтенләй дә булмады.

Безнең институт техник булганга күрә, төркемдә дә һәм, гомумән, уку йортында да егетләр күбрәк иде. Һәр студентның төркемдә үзенчәлекле яклары була. Мине иң оста шпаргалка ясаучы һәм күчерүче, дип йөрттеләр. Дөрестән дә, укытучылар ничек кенә тырышсалар да, минем елгырлыгым көчлерәк булгандыр – сиздерми идем. Әле дә хәтерлим: имтиханда төркемдәшләрем ишек ярыгыннан мине күзлиләр иде, янәсе, бу юлы нинди ысул кулланырмын. Шулай да дүртенче курста бер укытучы, имтихан алдыннан, башта кулымда булган бөтен нәрсәне икенче партага куйдырды. Үземне янә бер кат тикшерде, хәтта каләм белән кәгазьне дә башканы бирде. Алай да сынатмадым: барысы да уңышлы булды. Бөтен белгәнемне искә төшерә-төшерә язып, имтиханны «дүрт»легә биреп чыктым. Укытучының бу сабагы күңелемә шундый нык үтеп кергән: студентларымнан да нәкъ шуны таләп итәм.

Минем өчен студент чакта иң күңелле, иң истә калган мизгелләр төркемебез белән җыелып утырулар иде. Кураторыбызның теләсә-нинди уңайдан үз янына җыеп, кунак итә торган гадәте булды. Бергәләп су коендык, гитарада уйнадык, күңелле итеп аралаштык, паркларда җыелып кич утырдык... Бу мизгелләрне искә алганда, мине һәрчак үзенә күрә бер рәхәт сагыну хисе били...

Ә укып бетергәннән соң, мин училищега эшкә урнаштым. Кыскартуларга эләгеп аннан китәргә мәҗбүр булгач, өстәмә рәвештә психологияне үзләштереп, шул юнәлештә эшли башладым. Бүгенге көндә студентлар белән эшләү, аларга тормышта һәрчак кирәк булачак ситуацияләрне гап-гади телдә аңлату миңа чиксез рәхәтлек бирә! Алар белән аралашудан мин үземә ямь һәм тәм алам!..».

● Бәйге

# Без кино да төшерәбез!

Элвина НӘҖИПОВА,
татар филологиясе бүлеге

1 февраль көнне Филология һәм сәнгать институтында «Киномания» кыска метражлы фильмнар фестиваленең йомгаклау тантанасы узды.



■ *Конкурс җиңүчеләре жюри әгъзалары белән. Элвина Нәҗипова фотосы*

Филология һәм сәнгать институты студентларның талантларын төрле яклап сыный. Ә студентлар бер дә сынатмый, алар һаман нинди сәләтле булуларын дәлилләп тора.

Алты юнәлеш буенча эшләгән фестивальгә барлыгы тугыз эш тәкъдим ителгән. Аларны Дмитрий Второв–«Татарстан»телекомпаниясендә чыга торган «Вести» программасын алып баручы; Юлия Казанцева – «Яңа Гасыр» каналында бара торган «Закон. Парламент. Общество.» программасы авторы һәм алып баручысы, шул ук каналның генераль директор урынбасары, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе Зөфәр Закиров, институтның тәрбия һәм социаль эшләр буенча директор урынбасары Рөстәм Камалов бәяләде. Алар, яшь осталарның эшләренә нәтиҗә ясап, барлык катнашучыларны да котладылар, истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Безнең татар филологиясе бүлегенннән генә дә фестивальгә ике эш тәкъдим ителгән иде. «Социаль ролик» номинациясе буенча видеороликны «КАД» (3 курс студентлары: Әхмәтҗанова Диләнүр, Габдрахманова Руфинә, Сөнгатуллина Айгөл) төркеме әзерләде. Аларның тирән эчтәлекле «...в тебе» исемле роликлары барлык тамашачыны да таң калдырды. Безнең бүлек магистры Эльвира Һадиеваның «Син кирәк» исемле видеороликгы «Видеоклип» номинациясендә югары бәя алды.

Фестивальдә тәкъдим ителгән һәр эш үзенең нинди дә булса үзенчәлеге белән тамашачы күңеленә кереп калды. Бу фестиваль – студентларның фантазияләрен тагын да ныграк эшкә җигә һәм ныгыта торганнарның берсе, минемчә. Рөстәм Камалов: «Бу фестиваль үз йөзен югалтмаячак, ә киңрәк мәйданга чыгачак әле», – дип сөендерде. Киләчәктә аны университет күләмендә оештырырга ният кылулары билгеле булды.

● Хәтер яңартканда

# Үзебезнең «Джеймс Бонд»!



Гөлсем АБДУЛЛИНА,
хәбәрче

Нәкъ бер ел элек, 10 февраль көнне 91 яшендә якты дөньядан киткән Даян Баян улы Мурзин турында безнең илгә караганда читтә күбрәк тә беләләр бугай. Аның мактаулы исемнәре бихисап. Әлеге язмада Даян Мурзинның тормыш юлына күзәтү ясыйсым килә.

Даян Фәтхелбаян улы Мурзин – «Кара генерал», Бөек Ватан сугышында фашистларга каршы сугышкан партизан отрядлары оештырган легендар шәхес, Чехословакиянең Милли батыры, Адольф Гитлерның шәхси дошманы була.

Ул 1921 елның 20 гыйнварында Башкортстанның Бакалы районы Иске Балыклы авылында күп балалы гаиләдә (тугыз малай һәм бер кыз) дөньяга килә. Балачактан укытучы булырга хыяллана. Аеруча математика фәнен яратып укый. Мәктәптән соң, Кушнаренко педагогика училищесына белем алырга китә. Аны тәмамлап, авыл мәктәбендә мөгаллим булып эшли башлый. Ә Совет-фин сугышы башлану белән, Даян Мурзин үз теләге белән Кызыл армиягә языла. Уфада хәрби әзерлек узганнан соң, аны Ленинградта укыталар, соңрак Финляндиягә җибәрәләр. Ул арада, фин сугышы да тәмамлана.

Мурзин Ригадагы хәрби училищега укырга керә һәм Бөек Ватан сугышы башлануын, курсант буларак, чик буенда каршылый. Каты яраланып, чолганышта калганнан соң, дошман кулына эләгә. Савыккач, әсирләр лагереннән кача. «Ватан өчен» дигән партизаннар төркеменә кушыла. Бераздан аны разведка взводы командиры итеп билгелиләр. Отряд, фашист тылында партизаннар сугышын җәелдереп, кыю диверсион гамәлләр кыла. Гитлер армиясенең аэродром, корал складларын, күперләр һәм юлларын шартлаталар. Шунда ул икенче тапкыр яралана. Госпитальдән аны Украинага дошман тылына җибәрәләр.

1944 елда Мурзинны башта штаб начальнигы, аннан соң Ян Жижка исемендәге данлыклы партизаннар бригадасының командиры итеп билгелиләр. Тугыз дәүләт вәкиленнән, җиде йөз сугышчысы булган бригада немец протектораты астындагы Чехия белән Моравиядә фашистларга каршы партизан сугышы башлап җибәрә. Командир Ян Ушияк бәрелештә һәлак булгач, аның урынына 23 яшьлек Даян Мурзин билгеләнә.

Румыния һәм Венгрия чигендә канкойгыч сугышлар барганда, фюрер немец солдатларының күпләп кырылуына бик аптырый. Моны аңлау өчен, Адольф Гитлер үзе Прагага килә. Бөтен кешене җыеп, отчет таләп итә. Аңа Мурзин отрядының кыю, актив эшчәнлек алып баруы турында сөйлиләр. Гитлер ярты миллионлы немец армиясен куркуда тоткан «Кара генерал»ның башы өчен 3 миллион рейхсмарка вәгъдә итә. Бу эш өчен, гестапо армияне генә түгел, оккупацияләнгән территориядәге барлык халыкны эшкә җигә. Моравия, Чехия, Словакиядә самолетлардан Мурзин сурәте төшерелгән меңләгән листовка ташлыйлар. Ләкин Мурзин: «халык ул акчаларга мине сатмады», – дип яза. Мурзин отряды фашистларның борын төбеннән 16нчы танк армиясе командующие генерал Мюллерның үзен әсир итүгә ирешә һәм аның отряды генерал Власовны кулга төшерү буенча да уңышлы операция үткәрә. Мурзин бригадасы хәрби техникасы белән 68 эшелонны, меңнәрчә фашистны, 86 стратегик мөһим күперне юкка чыгара.

Сугыштан соң, Даян Мурзин озак еллар Башкортстан прокуратурасында хезмәт итә. Аннан БАССР Адвокатлар коллегиясенең рәисе вазыйфаларын үти. Тырыш хезмәте «Башкортстанның атказанган юристы» дигән мактаулы исем белән билгеләнә. Тынгысыз ветеран гомеренең соңгы көненә кадәр кул кушырып өйдә генә утырмый. Башкортстан республикасы Хокук саклау, кораллы көчләр, сугыш һәм хезмәт ветераннары советы президиумы рәисе дә, хөкемгә тартылучыларны аклау комиссиясе әгъзасы да булып тора.

Әйткәнемчә, үз батырларыбызны начар беләбез. Европа илләрендә Даян Мурзин турында китаплар язалар, ләкин әлеге көнгә кадәр аларның рус теленә тәрҗемәләре юк. Чехиянең Злин шәһәрендәге бер урам Даян Мурзин исемен йөртә. Чит ил халкы ватандашыбызны Джеймс Бонд белән чагыштыра, чөнки аның фронтта кылган батырлыклары әлеге әдәби герой маҗараларын да уздыра.

● Таныш бул!

# «Сары билбау»лы геофизик

**Динара МИННЕКАЕВА,**
хәбәрче

«Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз», дигән мәкаль бүген актуальлеген югалтты инде. Безнең заман егетләре йөз житмеш төрлесен дә үз итә. Яңа сәхифәбезнең бүгенге герое – Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институтының икенче курс студенты – Сәйдәш Камалиев.



Беренче карашка, кечкенәдән әдәби мохиттә үскән егетнең бу өлкәне сайлавы бик сәер тоелды миңа. Әбисенең (Элмира Шәрифуллина) иҗаты белән яхшы таныш, әнисендә укыган кеше буларак, Сәйдәшне башка төрле итеп күз алдыма китерә идем. Аралаша башлагач, киң җилкәле, баһадир гәүдәле егетнең эчке дөньясы мин уйлаганнан да мәдәниятлерәк булып чыкты.

Мәктәп елларында ук әдәбият буенча олимпиадаларда призлы урыннар яулаган укучы күңеле белән инженер булырга хыяллана. Анынча, егет кеше акча китерә торган һөнәр сайларга тиеш, ә башка максатларны, теләгең булса, болай да тормышка ашырырга мөмкин. «Хәтерлим: энем экспедициядән кайтты да бик кызыктырып сөйләде һәм шул вакыт нинди юнәлеш буенча китәчәгемне төгәл аңладым. Биредә укуыма сөенеп бетә алмыйм. Әлегә Татарстан буенча гына йөрдек, алга таба да үземне шушы өлкә буенча эшләрмен дип күз алдына китерәм», – ди яшь белгеч.

Сәйдәш – һәр яктан булган егет. Бүгенге көндә спорт буенча да уңышлары зур. 5 яшендә айкидо белән шөгыльләнә башлый, тырышлыгы нәтиҗәсендә «Сары билбау»га ия була. Икенче сыйныфтан каратэны үз итә. Бүгенге көндә дә бу спорт төре белән актив шөгыльләнә. Шәһәр, республика дәрәҗсендә генә түгел, Идел буе төбәкләре буенча узган ярышларда да сынатмый.

Сәйдәш көчле спорт төрләрен ярата булып чыкты. Ул 14 яшьтән бодибилдинг белән шөгыльләнә. «Миңа көч бирә торган спорт төрләре ошый. Алар дисциплинаны тәрбияли. Гадәттә, мондый спортчылар тыныч холыклы була һәм максатларны дөрес куя. Иң мөһиме: алар үзләреннән көчсезләргә тими», – ди Сәйдәш. Алай гына да түгел, ул һәр спорт төренең тарихын, төп үзенчәлекләрен белә.

Булганнан бар да була, диләр. Сәйдәш кул көрәше, биюнең джамстайл (Германиядә киң таралган) төре белән шөгыльләнә. Чит телләрне бик теләп өйрәнә. Инглиз, төрек телендә иркен аралаша. Махсус курсларга йөреп, тәрҗемәче булырга әзерләнә.

«Студент кеше укырга тиеш, синең моңа вакытың каламы?» – дип сорагач: «Үзем өчен башкарасы эшләр тәртибен төзим. Вакытны тигез бүләргә кирәк. Мин ял көннәрендә укуга бәйле бөтен эшләрне эшләп бетерәм», – дип җавап бирде.

Еш кына урамда эшсезлектән интегеп йөргән егетләрне күрергә туры килә. Яшь кенә малай-шалайларның кулларында тәмәке, сыра. Ата-ананың тир түгеп эшләгән акчасын җилгә очыручылар инде алар. Бу хәлләргә дә Сәйдәшнең үз фикере: «Танышларым арасында андыйлар бар. Әйтеп карагоаным да булды – тыңламыйлар. «Мода» артыннан куабыз дип, ахыры нәрсә белән бетәчәген уйламыйлар».

Кешедәге бөтен сыйфатлар да гаиләдәге тәрбиядән килә. Алма агачыннан ерак төшми, диләр. Ә Сәйдәш кебек алманың нинди агачта үскәнен сез дә күз алдына китергәнсездер.

● Дөнья үзебезнеке

# Әгәр без бу дөньяны дөрес яратабыз икән, димәк дөрес яшибез...

**Алинә САДЫЙКОВА,**
хәбәрче



Безнең йортта һәр яшәүчегә Жирле Мәченең никадәр кыяфәтсез һәм ямьсез икәне билгеле. Ул өч әйберне ярата иде: яшәү өчен көрәш, нәрсә эләксә, шуны ашау һәм мәхәббәт. Шулар аркасында аның тәнендә күпсанлы төзәлмәс яралар бар.

Кыяфәтсез Мәче бер генә күзле һәм бер генә колаклы иде. Сул аягы кайчандар сынып, дөрес ялганмыйча калган, шуның нәтиҗәсендә Мәче атлаганда кире якка борылыр сыман иде. Койрыгын да кайдадыр «югалткан»... Аның урынында бераз йонлы, кимерелеп бетә язган кечкенә генә бер нәрсә...

Ана карагач, һәркемдә бер үк уй туа: «бигрәк тә КУРКЫНЫЧ мәче»! Балаларга аның янына якын килү катгый тыела иде. Олылар аны, ераккарак куып җибәрү өчен, ташлар ыргыта, аның алдыннан гел дә ишекне ябып куялар. Безнең йорт тирәсен карый торган хатын аны шлангтан салкын су белән коендыруны үзенең бурычы дип саный.

Гаҗәп, әмма Кыяфәтсез Мәче бу хәлләргә үзенчә җавап кайтара иде... Әгәр аны шлангтан коендырсалар, ул җәзалаучы туйганчы тыныч кына чыланып тора. Берәр нәрсә ыргытсалар, ул, гафу үтенгәндәй, аякка сырпалана. Әгәр бала-чага күрсә, наз сорап, аларга таба йөгереп барып сырлалана һәм кычкырып мияулый. Әгәр аны кулга алсалар, шул кешенең күлмәк якасы, төймә яисә буе җиткән башка әйбере белән уйный башлый иде.

Беркөнне тәрәзәдән мин эт өргәнен, мәченең ярдәм сорап кычкырган тавышын һәм этләр хуҗасының «фас» командасын ишеттем дә аны коткарырга ыргылдым. Мин чыкканда, Кыяфәтсез Мәче таланып беткән, кан эчендә иде. Ул йомарланып яткан, аркасы, аяклары, тәненең арткы өлеше үз формасын бөтенләй югалткан, йөзендә күз яше эзе күренеп тора.

Өйгә алып кайткан вакытта, ул тончыга башлады. Ана тагы да зыян салырга курыксам да, йөгерә-йөгерә кайтырга тырыштым. Ә мәче минем колакны яларга маташты.

Мин туктадым һәм, күз яшьләремә буыла-буыла, аны кысып кочтым. Мәче башы белән минем кулыма кагылды, күзен миңа таба борды. һәм мин аның... мияулавын ишеттем!!! Шундый газаплы сызлануларына да карамастан, Мәче бер әйбер – БЕР ТАМЧЫ ЯРАТУ – сорады. Шул вакытта яратуга иң сәләтле җан иясе белән эш иткәнемне аңладым. Ул минем күзләремә туры карап, чын күңеленнән аның газапларын җиңеләйтә алуыма ышана иде.

Кыяфәтсез Мәче, өйгә кайтып җиткәнче, минем кулларымда җан бирде. Мин аны тоткан килеш бик озак утырдым һәм тирән уйларга чумдым...

Бер бәхетсез гарип җан чисталыгы, чиксез һәм тугрылыклы ярату турында күзаллауларымны үзгәртте. Кыяфәтсез Мәче миңа меңләгән китап, лекция һәм әңгәмәләргә караганда да күбрәк тәэсир итте. Мин ана мәңге рәхмәтле булачакмын, чөнки үзем өчен дә тугры һәм эчкерсез яратырга өйрәнер вакыт җиткәнлеген аңладым. Якыннарга бөтен назыңны биреп бетерергә кирәк икән.

Күпчелегебез баерак, матуррак, көчлерәк булырга тели.

Ә мин исә һәрвакыт бер әйбергә генә омтылачакмын: Кыяфәтсез Мәче кебек яратырга өйрәнергә...

*(Вадим Черноречин)*

● Әдәп-әхлак

# Бәхетле буласының - теле татлы

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Аралаша белү һәм матур сөйләшү әдәбе булдыру – шәхси тормышта да, башка өлкәләрдә дә кеше өчен бик кирәкле сыйфатларның берсе. Өйдәгеләр булсынмы ул, хезмәттәшләреңме – иң мөһиме үз фикереңне, теләк-тәкъдимнәреңне аңлаешлы итеп җиткерә белергә кирәк. Бары шул очракта гына әңгәмәдәшегезнең сезгә карата ышанычы артачак. Тормыш булгач, төрле хәлләргә очрыйсың. Кайвакыт сине тыңлап та тормыйлар яисә үзебез дә әңгәмәне кирәксез урында өзәргә мөмкин. Шуны истә тотарга кирәк: сөйләшү әдәбенең дә үз кагыйдәләре бар.

Беренчедән, сөйләшкәндә, артык кычкырмагыз һәм артык әкрен дә сөйләмәгез. Адәм баласының күңелендә булган йомшаклык һәм катылык сыйфатларын, гыйлемле, әдәпле, мәгърифәтле булуын тел күрсәткәнне уегыздан чыгармаска кирәк.

Икенчедән, һичкайчан арттырып, ялган һәм гайбәт сүзләр йөртеп, белмәгән нәрсәләрне дә сөйләргә тырышмагыз. Бер кеше сүз башласа, ахыры сезгә мәгълүм булса да, сүзе бетмәс борын тыңламыйча китү дә әдәпсезлек билгесе. Ә инде башка берәүнең ялгыш сөйләвен күреп алсагыз, «белмисең», «ялган сөйлисең», дип күңеленә авыр булырлык итеп әйтергә ярамый. Кеше күңеленә авырлык килми торган итеп йомшаклык белән дөреслекне күрсәтегез.

Тагын бер алтын кагыйдә бар: үзегезнең ялгыш сөйләвегез беленсә, «ялгыштым» дип әйтүдән беркайчан да гарьләнмәскә кирәк. Ә олыларга мөрәҗәгать иткәндә, «сез» сүзен ешрак кулланыгыз. Шулай итеп үзегезгә карата хөрмәтне арттырырсыз гына. Фикер әйтергә теләсәгез, иң элек мәсьәләне яхшы аңлагыз, шуннан соң гына тәрбияле итеп әңгәмәдәшегезгә җавап кайтарырга мөмкин.

Кешеләр белән бәхәсләшүдән дә ераграк торыгыз. Синең белән начар мөгамәлә итүчеләр белән игелекле булып, синең файдага булмаганда да, дөресен сөйләү зарур.


Сөйләшкәндә, күпләр бер типик хата ясый. Ул – берничә эшне берьюлы эшләргә омтылу. Кешене тыңлау, шул ук вакытта сумкада эзләнү , я булмаса телефонда нидер эшләү – бик ямьсез күренеш. Әгәр дә инде кичекмәстән китәргә кирәк икән, әдәпле генә гафу үтенеп, үз юлыгызда булыгыз.

Иң мөһиме: әңгәмәдәшегезгә һәрвакыт ягымлы һәм тәрбияле итеп җавап кайтарыгыз! Кешенең ни дәрәҗәдә әдәпле булуын аның теле күрсәтә!

● Спорт

# КФУ баскетболистлары янә алда

**Алсу ГӘРӘЕВА,**
Экология һәм география институты



Узган атнада ир-ат командалары арасында баскетбол ярышларының икенче туры башланды. Шимбә көнне КФУның җыелма командасы КДАУ командасы белән очрашты. Беренче таймда ике команда да көчләрен артык сарыф итмичә, ләкин шул ук вакытта берберсенә бирешмичә уйнады. Нәтиҗәдә, 8:9 исәбе белән КДАУ командасы өстенлек алды. Алга таба уен кызганнан-кыза барды. Туп оста уенчылар кулыннан әле бер, әле икенче кәрзингә оча торды. Әйтергә кирәк, ике команданың да җыйнак һәм бердәм эш итүе, кирәк чакта көч һәм җитезлек күрсәтүе уенны тагын да мавыктыргыч итте.

Икенче өлештә өстенлек КФУ командасында булса, өченчесендә авыл хуҗалыгы студентлары дилбегәне үз кулларына алды. Соңгы период, чын мәгънәсендә, көчле алыш булды. Уен азагына кадәр, кем җиңәчәге билгеле түгел иде. Каннары кызган уенчылар соңга таба кайбер кагыйдәләрне бозсалар да, туп атуда барлык осталыкларын күрсәтеп, ахыргача көрәште. Уен безнекеләр файдасына 61:57 исәбе белән тәмамланды.

Икенче көнне университетыбыз баскетболистлары КДЭУ җыелма командасы белән очрашты. Энергетикларның көче азрак иде. Безнекеләр беренче өлештә үк матч барышын үз кулларына алды. Уен күберәк каршы як кәрзин янында бөтерелде. Энергетик иптәшләрнең каршылыгы озакка җитмәде. Хөкемдар уен ахырын белдергән сыбызгы тавышын яңгыратканда, табло безнекеләр файдасына 70:44 исәбен күрсәтә иде.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова, З.Ф.Фәсхиева
Корректор Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.